ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

14 июнь 2018 ел

**КАРАР**

№ 3382

Башкарма комитетның «Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертелгән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрен социаль ипотека системасында торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен түләүсез бирү хакында карарлар кабул итү тәртибе турында» 2009 елның 3 апрелендәге 1308 нче карары үз көчен югалткан дип тану турында

Яр Чаллы шәһәре прокурорының 2018 елның 6 июнендәге 1104вх2018 нче протестын караганнан соң, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ санлы Законының 6.1 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.21 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертелгән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләрен социаль ипотека системасында торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен түләүсез бирү хакында карарлар кабул итү тәртибе турында» 2009 елның 3 апрелендәге 1308 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин